# Образование
## Нижнекамского муниципального района

2018

# ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА
# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУ ТОРЫШЫ
# 2017-2018 НЧЕ УКУ ЕЛЫ



***Исмәгыйлова Резедә Раиф кызы***



***Сабирова Гөлүсә Мөхәмәтхәсән кызы***

*Исмәгыйлова Резедә Раиф кызы, Сабирова Гөлүсә Мөхәмәтхәсән кызы, Түбән Кама шәһәре мәгариф идарәсен укыту-методик яктан тәэмин итү бүлеге методистлары*

Халыкның үлемсезлеге-аның телендә
*Ч.Т. Айтматов*

Кешелек тарихында туган телен югалткан халыкларның бөтенләй юкка чыгу очраклары бик күп теркәлгән. Тел халыкның асылын, фикерләү һәм яшәү рәвешен, әхлагын чагылдыра. Һәр халыкнын да рухи мәдәниятендә туган тел төп урынны алып тора.

Татарстан Республикасының Төп Законы нигезендә, 1990 нчы елдан башлап, җөмһүриятебездә ике дәүләт теле - рус һәм татар телләре - мәктәпләрдә тигез күләмдә укытылды.

*2016-2017 нче уку елы нәтиҗәләренә анализ ясаганнан соң, түбәндәге бурычлар куелды:*

1. “2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Дәүләт программасын сыйфатлы итеп тормышка ашыру;
2. Татар телендә белем һәм тәрбия бирүче 1 нче сыйныфларны ачу юнәлешендә балалар бакчалары һәм мәктәпләр арасында дәвамчанлыкны тәэмин итү эшчәнлеген активлаштыру;
3. Татар сыйныфларында укытуны туган телдә оештыру, аларда татар теленең статусын уку-укытуның төп теле итеп раслау;
4. Милли мәгариф системасын укытучыларның һөнәри белемнәрен күтәрү аша камилләштерү; инновацион педагогик технологияләр кулланып, татар телен өйрәнүнең сыйфатын күтәрү;
5. Укытучыларны яңа методик алымнар кулланып эшләүгә тарту, В.Н. Мещерякова технологиясен гамәлгә кертүгә ирешү;
6. 1 нче сыйныфларда “Сәлам” укыту-методик комплектын куллануны тормышка ашыру;
7. Педагогик остаханәләрдә БРТ на әзерлек алып бару;
8. Укучыларның иҗади сәләтләрен ачу, аларда белемгә һәм камиллекккә омтылыш, әхлакый сыйфатлар формалаштыру.

2017-2018 нче уку елы башына 53 укыту учреждениесендә (кечке һәм коррекцион мәктәпләрдән тыш) 28 528 укучы белем алды.

**Милли состав:**

| Милләт | Укучылар саны | % |
|---|---|---|
| Руслар | 12247 | 42,9% |
| Татарлар | 10344 | 36,2% |
| Чувашлар | 440 | 1,5% |
| Башкортлар | 78 | 0,2% |
| Украиннар | 43 | 0,1% |
| Таҗиклар | 98 | 0,3% |
| Үзбәкләр | 67 | 0,2% |
| Әзәрбайҗаннар | 66 | 0,2% |
| Әрмәннәр | 67 | 0,2% |
| Башка милләтләр | 172 | 0,6% |
| Катнаш гаиләләр | 4848 | 16,9% |

Татар телен укытуның һәрдаим төп бурычы - татар балаларын туган телдә укытуның даирәсен киңәйтү.

Түбән Кама МР татар телендә белем бирүче 6 милли мәктәп (гимназия №№1,2, Каенлы, Югары Чаллы, Шәңгәлче, Түбән Уратма) һәм чуваш телендә белем бирүче 1 мәктәп эшләп килә. Татар мәктәпләрендә 1860 укучы белем ала (2016-2017 нче уку елында – 2097), 34 нче гимназия-интернатта чуваш телен 248 укучы өйрәнә.

Түбән Кама МР буенча татар телендә белем бирү уку елы башында 33,5 % тәшкил итте. (2016-2017 нче уку елында – 31,7%).

**Татар телендә белем бирүнең соңгы 5 ел эчендәге күрсәткечләре**

| | Уку елы | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | **2013-2014** | **2014-2015** | **2015-2016** | **2016-2017** | **2017-2018** |
| Татар балалары саны | 10669 | 9987 | 9800 | 10057 | 10344 |
| Туган телдә белем алучылар саны | 3054 | 2997 | 3087 | 3189 | 3474 |
| **%** | **28,6** | **30** | **31,3** | **31,7** | **33,5** |

Түбән Кама МР мәгариф идарәсе планы нигезендә уку елы дәверендә балалар бакчалары белән мәктәпләр арасында дәвамчанлыкны тәэмин итү юнәлешендә эшчәнлек алып барыла. Татар теле укытучылары чыгарылыш төркемнәрендә ата-аналар өчен җыелышларда чыгыш ясыйлар, ата-аналарны кызыксындыру һәм балаларын татар сыйныфларына җәлеп итү максатыннан, мастер-класслар, видео-дәресләр күрсәтәләр.

**1 нче татар сыйныфларын ачу буенча мәгълүмат**

| Уку елы | 2013-2014 | 2014-2015 | 2015-2016 | 2016-2017 | 2017-2018 |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 нче сыйныфлар саны | 18 | 19 | 23 | 21 | 27 |
| Укучылар саны | 371 | 414 | 512 | 472 | 621 |

Соңгы 5 ел эчендәге күрсәткечләргә караганда, эшчәнлектә уңай динамика күзәтелә, әлеге дәвер эчендә татар сыйныфларында укучы балалар саны 9 сыйныф-комплектка, ягъни 248 укучыга арткан.

2013-2014 нче уку елыннан башлап, “Татар теле” предметыннан Татарстан Республикасы мәктәпләренең 9 нчы сыйныфларында белем алучы барлык укучы мәҗбүри рәвештә Бердәм Республика Тестын тапшырды. Укучыларның белемнәрен тирәнәйтү, педагогларның осталыкларын үстерү максатыннан, әлеге юнәлештә байтак эш башкарылды. 2016-2017 нче

уку елында татар теле укытучыларының педагогик остаханәсе нәкъ менә Бердәм Республика Тестын уңышлы тапшыру, ягъни укучыларның белемнәрен тирәнәйтү йөзеннән оештырылды. Әлеге төркемдә югары һәм беренче квалификацион категорияле укытучылар 8 нче, 9 нчы сыйныфларда белем бирүче педагогларга методик ярдәм күрсәтте, бердәм республика тестына әзерлек буенча төпле киңәшләр бирелде.

В 2016-2017 уку елында муниципаль район буенча 3 педагогик остаханә эшләде.Остаханәләрнең эшчәнлеге отышлы булды: 2013-2014 нче уку елында БРТ нәтиҗәләренең уртача күрсәткече - 3,49; 2014-2015 нче уку елында – 3,47; 2015-2016 нчы уку елында – 3,5; 2016-2017 нче уку елында 3,61 балл тәшкил итте.

**БРТ нәтиҗәләренең соңгы 3 ел эчендәге күрсәткечләре**

| Уку елы | 9 нчы сыйныф укуч. саны | “5” | “4” | “3” | “2” | өлгереш | сыйфат | уртача билге |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2014-2015 | 2508 | 276 | 851 | 1147 | 234 | 90,7 | 44,9 | 3,47 |
| 2015-2016 | 2433 | 335 | 712 | 1223 | 164 | 93,3 | 43,03 | 3,50 |
| 2016-2017 | 2467 | 378 | 910 | 1017 | 164 | 93,4 | 52,2 | 3,61 |

Сәләтле балалар үсешен булдыру юнәлешендә укучылар өчен төрле дәрәҗәдәге олимпиадалар оештырыла. Әлеге юнәлештә татар теле укытучыларының максатчан эшчәнлекләре укучыларның уңышлары белән билгеләнә. Түбән Кама МР укучылары татар теле буенча төрле юнәлештәге республика олимпиадаларында 13 призлы урын яуладылар. 2009-2010 нчы уку елы белән чагыштырсак, ул дәвердә призерлар саны 5 кенә укучы иде.

**Олимпиадаларда катнашуның соңгы 3 ел эчендәге күрсәткечләре**

| Уку елы | Призлы урыннар саны | Укыту оешмалары |
|---|---|---|
| **2015-2016** | 21 | Гимназияләр №№1,2,13,32, Каенлы мәктәбе, Кама Аланы №2, лицей-интернат №24, лицей 35, №№ 5, 12, 33 нче мәктәпләр |
| **2016-2017** | 19 | Гимназияләр №№1,2,13,32, Каенлы мәктәбе, лицей-интернат №24, лицей 35, №№ 5, 19, 33 нче мәктәпләр |
| **2017-2018** | 13 | Гимназияләр №1,2, 13, 32; лицей №24, 35; Каенлы мәктәбе |

Татар теленең статусын күтәрү максатыннан, 2012 нче елдан башлап, ТР М һ ФМ Халыкара олимпиада үткәрә. 2017-2018 нче уку елында йомгаклау сынавына районыбызның 7 укучысы чакырылды, 1 нче гимназиянең 1 укучысы лауреат булу дәрәҗәсенә иреште.

2018 нче елның 25 нче апрелендә Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында яшь язучыларның Бөтенрәсәй “Илһам” бәйгесе җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы булды. Әлеге чара татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен саклау һәм үстерү, укучыларда әдәбиятка, сәнгатькә кызыксыну уяту, әдәби иҗатка сәләте булган яшьләрне ачыклау, барлау, яшь язучыларны таныту, осталыкларын үстерергә ярдәм итү максатыннан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Язучылар берлеге, Казан федераль университеты белән берлектә оештырыла. Бүләкләү тантанасында 27 нче һәм Югары Чаллы мәктәпләрендә укучылар катнашты. 27 нче мәктәп укучысы Гыймранова Диләрә 2 урынга лаек булды, Югары Чаллы мәктәбе укучысы Нәфыйкова Рания бәйгенең лауреаты булу дәрәҗәсенә иреште.

**Татар теленнән Халыкара олимпиада күрсәткечләре**

| Уку елы | Призлы урыннар саны | Уку йорты | Укучы | Педагог |
|---|---|---|---|---|
| 2015-2016 | 2 | 2 нче гимназия | Хәсәншина Ләйлә (2 нче урын), Сабирова Ләйсән (3 нче урын) | ЗариповаА.Г., Шәймөхәммәтова Ф.М. |
| 2016-2017 | 1 | 35 нче лицей | Андрющенко Елена (лауреат) | Хуҗанбердиева Ч.Т. |
| 2017-2018 | 1 | 1 нче гимназия | Сөнгатуллина Фәридә (лауреат) | Сөнгатуллина Л.М. |

Әдәбият өлкәсендә яшь талантларны үстерү, аларга беренче адымнарын ясарга ярдәм итү - милли мәгарифнең бурычы. Шул максаттан, шәһәребездә 1998 нче елдан бирле Р.И. Вәлиев премиясенә яшь язучылар бәйгесе үткәрелеп килә. 20 ел эчендә каләм тибрәтүчеләр бәйгесендә 1781 укучы катнашты. 2017-2018 нче уку елында жюри әгъзалары игътибарына 44 эш кабул ителде. Җиңүчеләрне “Кама таңнары” әдәби берләшмәсе әгъзалары составындагы мәртәбәле жюри билгеләде. Май аенда И.Х. Садыков исемендәге иҗат Сараенда бәйгенең бүләкләү тантанасы оештырылачак. Тантанада шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе Р.И. Вәлиев шәхсән үзе дә катнашачак.





Татар халык, классик, заман җырларын популярлаштыру, сәләтле балаларны ачыклау һәм аларның үсеше өчен шартлар тудыру, татар теленә, татар халкының композиторларына, шагыйрьләренә һәм аларның әсәрләренә карата мәхәббәт тәрбияләү максатыннан, ел саен шәһәребездә Бөтендөнья татар конгрессы ярдәме белән 10 ел дәверендә “Көйле, моңлы татар җыры” бәйгесе үткәрелә. Җыр бәйгесендә һәр ел меңнән артык бала катнаша. 2017-2018 нче уку елында 1022 укучы катнашты. Сайлап алу турында уңай нәтиҗәләргә ирешкән хор коллективлары, ансамбльләр йомгаклау кичәсенә чакырыла, Бөтендөнья татар конгрессының Түбән Кама бүлеге рәисе Р.М. Ганиев тарафыннан тантаналы рәвештә бүләкләнә. Әйтергә кирәк, “Көйле, моңлы татар җыры” бәйгесендә катнашу белем бирү оешмалары өчен зур стимул булып тора. Җиңү бәхетенә ирешкән мәктәпләр акчалата бирелгән премия хисабына милли костюмнар тектерә. Алар, мәктәп күләмендә генә түгел, муниципаль дәрәҗәдә үткәрелә торган чараларның йөзе булып тора.

 

Тел һәм әдәбиятны саклау һәм үстерү максатыннан ТР һәм Түбән Кама муниципаль районы җирлегендә 18 ел дәвамында Туган тел көнен билгеләп үтү матур традициягә әйләнде. Февраль аенда, нәкъ менә 21 нче февральдә бөтен дөньяда Халыкара туган тел көне билгеләп үтелә бит.

Шунысын да әйтергә кирәк, Түбән Кама муниципаль районында төрле милләт халыкларының 33 вәкиле яши. Аларның балалары шәһәр һәм район мәктәпләрендә белем ала. Чараларның максаты – укучыларда туган телне өйрәнүгә кызыксыну уяту, туган телне саклауның әһәмиятен төшендерү, үз халкыңның традицияләре һәм мәдәниятенә хөрмәт белән карау, телләр өйрәнү аша төрле халыкларның мәдәниятләре белән танышу, аралашу күнекмәләре формалаштыру.

Туган тел декадасын үткәрүгә бәйле рәвештә педагоглар алдына түбәндәге бурычлар куела:

- туган телне өйрәнүгә кызыксынуны арттыру;
- төрле чараларның югары методик дәрәҗәдә үткәрелүенә ирешү;
- белем һәм тәрбия бирү бурычларын тормышка ашыруда укучыларның яшь үзенчәлекләрен истә тотып эш итү;
- педагогик осталыкны үстерү;
- дәресләрдә һәм сыйныфтан тыш чараларда укучыларда югары рухи- әхлакый сыйфатлар формалаштыру;
- иҗади потенциалны үстерү аша укучыларда үз-үзенә ышаныч, тормышка ачык караш булдыруга омтылу.

Ел саен гыйнвар ае башында һәр уку йорты Туган телләр декадасын үткәрү планын тәкъдим итә. Әлеге чараларның күбесе Түбән Кама муниципаль районы башлыгы И.Р.Метшин раслаган муниципаль планга кертелә. Быел да Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты белән берлектә гомуми план төзелде, монда мәктәп һәм һөнәри белем бирү уку йортларының иң яхшы дип табылган чаралары да кертелде. Барлыгы 86 чара тәкъдим ителде.

Күп мәктәпләрдә Туган телләр декадасы ачылуга багышланган тантаналы линейкалар, сыйныф сәгатьләре, ачык дәресләр үткәрелде. Белем бирү оешмалары туган тел турында бөек кешеләр әйткән сүзләр, афоризмнар, “Туган телгә Гимн”, “Туган телем – иркә гөлем” һ.б темаларга чыгарылган стена газеталары белән бизәлде.

Халыклар дуслыгы фестивален үткәрү төрле милләт укучыларын берләштерергә ярдәм итә. 15, 16нчы февральдә 25нче гимназиядә һәм 35нче лицейда ел саен үткәрелә торган Дуслык фестивале булып узды. 5-11нче сыйныф укучылары арасыннан төрле милләт вәкилләренең 12 коллективы чыгыш ясады. Алар арасында рус, татар, чуваш, үзбәк, таҗик, әрмән, удмурт һәм башка милләт вәкилләре урын алдылар. Үсеп килүче яшь буын үзенең туган телен, мәдәниятен, үткәнен белергә тиеш. Шуңа күрә дә, аларда туган халыкка, туган төбәккә мәхәббәт, халыкның үткәненә ихтирам, бөек шәхесләр иҗаты белән кызыксыну кебек сыйфатлар тәрбияләү зарур.

Туган телләрне, милли мәдәниятләрне саклап калу һәм үстерү өчен, милләтара мөнәсәбәтләрне ләззәтләндереп, гражданлык бердәмлеген һәм илнең бөтенлеген тәэмин итүне, әйдәп баручы звено булып, мәгариф системасы тора. Балаларда милли горурлык

тәрбияләүнең иң мөһим чарасы булып, пропагандалау, традицион мәдәният, танылган язучылар тора. Шәһәр мәктәпләрендә шагыйрь М.Җәлилгә, язучы Гаяз Исхакыйга, шагыйрә Әлфирә Фәтхетдиновага багышлап әдәби кичәләр, “Кама таңнары” әдәби берләшмәсенең язучылары белән әдәби очрашулар узды.

Белгәнебезчә, 2018 нче елда бөек рус язучысы Л.Н. Толстойның тууына 190 ел булды. Мәшһүр язучы иҗатының йогынтысы рус һәм дөнья әдәбиятына бихисап. Шулай ук Толстойларның гаилә тарихы Казан белән бәйле. Киң җәмәгатьчелек игътибарын мәдәният һәм тел белеме үсешенә җәлеп итү максатыннан 2018 нче ел Л.Н. Толстой елы дип игълан ителде. Декада көннәрендә язучыга багышлап күп кенә чаралар үткәрелде. Аларның кайберләрен генә санап китәбез: тантаналы линейкалар, стена газеталары, сәнгатьле уку, сыйныф сәгатьләре, әдәби кунакханә һ.б.

Мәктәпләрнең иҗади коллективлары үзләренең осталыкларын җыр һәм бию жанрында күрсәттеләр. Белем бирү оешмаларының һәрберсендә диярлек конкурслар үтте. Анда шәһәрнең төрле милли – мәдәни берләшмәләре катнашты. Бу конкурсларны үткәрүдә Халыклар дуслыгы йортының да өлеше бик зур. Без Халыклар дуслыгы йорты белән инде берничә ел эшләп киләбез. Анда мәктәп укучылары еш кына төрле чараларга чакырылалар.

Сәләтле балаларны билгеләү максатыннан башлангыч һәм урта звенолар арасында “Минем Татарстаным”, “Туган ягымны яратам”, “Туган ягым – яшел бишек” темаларына рәсем конкурслары игълан ителде.

Шулай ук, яраткан милли халык ашлары турында әйтмәү мөмкин түгел. Биредә балалар турыдан-туры теге яки бу халыкның культурасы һәм традицияләре белән танышып кына түгел, ә үзләре яраткан ризыкларның тәмен дә татып карыйлар.

Туган телне саклап калу һәм үстерү, яшьләр арасында тирәнтен уйланылган, күпкырлы эшне таләп итә. Мәктәп һәм шәһәр китапханәчеләре Туган тел көненә багышланган тематик китап күргәзмәләре, шулай ук, “Татарстан язучылары - балаларга", Туган тел сандыгы”, “Без сине саклыйбыз, “Рус теле, бөек рус сүзе” дигән китапханә дәресләре уздырдылар. СПО студентлары, Туган тел декадасында, музейларга экскурсиягә баруны актив оештырдылар.

20 нче февральдә 34нче номерлы чуваш гимназиясендә регионара “Нәрсә? Кайда? Кайчан?” фикерләү сәләтен үстерүче (интеллектуаль) уен үткәрелде. Биредә Аксубай районыннан “Савгач”, Бөгелмә районыннан “Наратлы”, Чирмешән районыннан “Иске Элмәле” һәм “Ивашкино” урта мәктәпләре, Түбән Камадан 34нче интернат-гимназиясе һәм И.Н. Ульянов исемендәге Чуваш дәүләт университетының рус һәм чуваш филология һәм журналистика факультеты студентлары командалары катнашты. Уен туган телләр көненә, Л.Н.Толстой һәм Волонтерлар елына, чуваш мәгърифәтчесе И.Я.Яковлевның юбилеена багышланган иде. Бәйрәм дәвамында И.Н. Ульянов исемендәге Чуваш дәүләт университеты укытучылары, чуваш шагыйре, якташыбыз Михаил Краснов кебек кунаклар тарафыннан ясалган чыгышлар чуваш телендә яңгырады.

Телне саклау – бик мөһим мәсьәлә. Ана теле бала өчен иң газиз тел ул. Туган телләр декадасын уздыруда иң актив катнашучылар - укучыларның әти-әниләре.

Туган телләр декадасын тәмамлаганда, Түбән Кама МР оешмаларының барсында да бердәм туган телләр көне үткәрелә. Бәйрәмгә укучыларның әти-әниләре, милли - мәдәни оешма, Аксакаллар шурасы вәкилләре чакырыла.

22нче февральдә Туган телләр декадасы тәмамлана. Барлык уздырылган чаралар Инстаграмм социаль челтәрләрендә, белем бирү оешмаларының сайтларында яктыртылды. Икетеллелекне саклау максатыннан, иң әһәмиятле чаралар ике дәүләт телендә дә рәсмиләштерелде.

Барлык Туган телләр декадасында катнашучылар да телнең милли мәдәниятне чагылдыручы корал, рухи һәм матди мирасыбызны үстерүдә һәм саклауда төп корал булып торуы турында уйланганнардыр, мөгаен.

Һәр халыкның теле үзенчәлекле, милләтнең менталитетын һәм гореф-гадәтләрен чагылдырган үзенчәлекле төсмергә ия.

ТР М һ ФМ алдынгы укытучыларны барлау өлкәсендә колачлы эш алып бара. Соңгы 2 елда укытучыларның һөнәри үсешен тәэмин итү грантлары буенча бәйгедә татар теле укытучылары актив катнашты.

**2016-2017 нче уку елында ТР М h ФМ гранты ияләре турында мәгълүмат**

| Түбән Кама МР Башлыгы гранты | Өлкән укытучы | Укытучы-мастер | Укытучы-эксперт |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 2 | 3 |

Һөнәри бәйгеләрдә катнашу – педагогларның һөнәри үсеш дәрәҗәсен билгеләүче өлге булып тора. Шундыйларның берсе – туган тел укытучыларының Бөтенрәсәй “Туган тел” мастер-класслары бәйгесе. Агымдагы уку елында 14 нче лицейның татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мифтахова Эльмира Флүр кызы номинациядә җиңүче дип табылды.

Хәзерге үзгәрешләр заманында, күп өлкәләрдә яңалыклар туып торганда, заман укытучысына үз профессиональ дәрәҗәсен үстерү өстендә өзлексез эшләргә туры килә. Бәйгеләрдә катнашулардан тыш, татар теле һәм әдәбияты укытучыларының күпчелеге үзбелемнәрен күтәрү өстендә актив эш алып баралар, матбугат битләрендә эш тәҗрибәләре белән уртаклашалар. 3 ел дәвамында укытучылар “Мәгариф”, “Гаилә һәм мәктәп”, “Мәгариф. Татар теле” журналларына альтернатив язылуда актив катнашалар. Бу эш 13 нче гимназия, 5, 20, 21 нче мәктәпләр нигезендә оештырыла.

Шулай итеп, түбәндәге нәтиҗәгә килергә мөмкин: 28 ел эчендә укучылар һәм әти-әниләр тарафыннан татар теленә мөнәсәбәт уңай якка үзгәрде, укыту сыйфаты күтәрелде, алдынгы технологияләргә таянып укыту сәбәпле, татар теле дәресләренең эчтәлеге яңарды һәм укучыларда тел белән кызыксыну артты.

2017 нче елның 20 нче июлендә Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин Йошкар-Оладагы чыгышында регионнарда милли телләрне, шул исәптән милли дәүләт телен дә мәктәпләрдә ирекле укыту кирәклеге турында әйтте һәм: “Кадерле дуслар, шуны исегезгә төшерергә телим: рус теле безнең өчен – дәүләт теле, халыкара аралашу теле һәм аны бернинди тел белән дә алыштырып булмый. Ул безнең күпмилләтле ил өчен табигый рухи нигез. Аны һәркем белергә тиеш”-, дип белдерде. Президент В.В. Путин Генераль прокуратурага милли телләрне теләк буенча өйрәнү мәсьәләсен тикшерүне йөкләде һәм төбәк җитәкчеләренә бу мәсьәләгә игътибар итәргә кушты. Бу белдерүдән соң, 2017 нче елның октябрь аеннан башлап, мәктәпләрдә татар телен укыту буенча Россиядә мәгариф өлкәсендә күзәтчелек учреждениесе (Рособрнадзор) белән бергә прокуратура тикшерүләре башланды. Алар фикеренчә, республика мәктәпләрендә рус теле тиешле күләмдә укытылмаган. Региональ прокуратура тарафыннан республика мәктәпләре алдына татар телен мәҗбүри укытуны тыю һәм факультатив дәресләргә генә калдыру таләпләре куела башлады. Шунлыктан мәктәпләр укыту планнарына төзәтмәләр кертергә мәҗбүр булды: татар теле “Туган тел һәм туган әдәбият” предметы белән алыштырылды һәм укучыларның нинди туган телне өйрәнәчәген хәл итү әти-әниләр ихтыярына тапшырылды.

2017-2018 нче уку елының 2 нче чиреге башыннан үткәрелгән чаралар нәтиҗәсендә, ТР мәктәпләренең барысында да укыту планнарына үзгәрешләр кертелде, “Татар теле һәм әдәбияты” предметы “Туган тел һәм туган әдәбият” статусына үзгәртелде. Шул рәвешле, 51 % укучы -татар телен, 48 % - рус телен, 1% чуваш телен туган тел буларак өйрәнү өчен сайлады. Укыту планындагы үзгәрешләр татар теле һәм әдәбияты укытучыларының укыту сәгатьләре күләменең кимүенә китерде.

Уку елы башына район күләмендә 305 татар теле һәм әдәбияты укытучысы исәпләнде. 224 педагог (73,4%) югары яки беренче квалификацион категориягә ия.

**Татар теле һәм әдәбияты укытучылары турында соңгы 3 ел эчендәге мәгълүмат**

| Уку елы | Барлыгы | Югары кв. категория | I кв. категория | СЗД |
|---|---|---|---|---|
| **2015/2016** | 313 | 44 (16%) | 192 (61,3%) | 77 (24%) |
| **2016/2017** | 318 | 38 (12%) | 201 (63,2%) | 74 (23%) |

| **2017/2018** | 305 | 33 (10,8%) | 191 (62,6%) | 81 (26,5) |
|---|---|---|---|---|

Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының укыту сәгатьләре күләменең кимүе сәбәпле, ТР М һәм ФМ тарафыннан укытучылар өчен төрле юнәлешләр буенча яңадан әзерләү курслары оештыру карары кабул ителде. Бүгенге көндә 137 (45%) укытучы "Башлангыч мәктәп", "Мәктәпкәчә белем алу" юнәлешләре буенча укуларын тәмамлап килә. Аларның уртача яше 37-50 яшь тәшкил итә.

**Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының яшь категориясе**

| 30 яшькә кадәр | 30-40 яшь | 40-50 яшь | 50-60 яшь | 60 тан югары |
|---|---|---|---|---|
| 22 | 69 | 118 | 86 | 7 |



Теләсә нинди фәнгә мәхәббәт, аны тирәнтен өйрәнергә омтылыш иң элек бу фәннән белем бирүче укытучыдан башлана. Балаларда туган телне өйрәнүгә омтылыш, кызыксындыру тудыру - бүгенге көн кадагында торган төп максат. Оста укытучы, укучының теге яки өлкәдәге кызыксынуларын күреп, ачып, аны тагын да үстерә ала. Татар теле һәм әдәбияты укытуның нәтиҗәлелеген арттыру, укыту методикасын камилләштерү – бердәм көч белән генә хәл ителә ала торган мәсьәлә. 2016-2017 нче уку елында "Татар теле - яраткан предметым" дип аталган муниципаль проект эшләнде. Мәгариф идарәсе тарафыннан 31 нче мәктәп җирлегендә татар теле һәм әдәбияты укытучыларын Ә.З. Рәхимовның иҗади үсеш технологиясенә өйрәтү буенча педагогик остаханә ачу карары кабул ителде. Аның җитәкчесе итеп, татар теле һәм әдәбияты укытучысы, акмеолог Р.А. Шәйхетдинова билгеләнде. Укытучы педагогик остаханәнең планын төзеде, Түбән Кама МР ның татар теле һәм әдәбияты укытучыларыннан торган иҗади төркем оештырылды. Остаханәнең эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак, Яр Чаллы педагогик университеты галимнәре белән берлектә оештырылган республика семинары узды. 2017-2018 нче уку елында татар теле һәм әдәбияты укытуны камилләштерү буенча төзелгән "Юл картасы" (№431, 26.09.2017); Ә.З. Рәхимов технологиясенә таянып укыту торышын тикшерү буенча мәгариф идарәсе боерыгы (№460, 12.10.2017) һәм "Татар теле - яраткан предметым" дип аталган муниципаль проектны гамәлгә ашыру нигезендә, 2017 нче елның 18 нче октябреннан 21 нче декабрена кадәр Ә.З. Рәхимовның иҗади үсеш технологиясен куллану буенча укулар үткән укытучыларның эшчәнлеген тикшерү оештырылды. Тикшерү барышында 1, 2, 13, 22, 25 нче гимназияләрдә, 14, 35 нче лицейда; 6, 21 нче мәктәптә - дәресләр, 3, 9, 15, 16, 20, 26, 27, Кама Аланының 1, 2 нче мәктәпләреннән тәкъдим ителгән видеодәресләр каралды. 2018 нче елның 11 нче маенда 6 нчы мәктәп җирлегендә татар теле һәм әдәбияты укытучыларының мәктәп методик берләшмәләре җитәкчеләренең утырышы булды. Монда Түбән Кама МР да Ә.З. Рәхимов технологиясен гамәлгә ашыру буенча тьюторлар билгеләнде.

Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының педагогик компетентлыгын арттыру юнәлешендә Түбән Кама муниципаль районында колачлы эш алып барыла. Бигрәк тә ТР М һ ФМ тарафыннан рус телле балаларга татар телен өйрәтү методикасын камилләштерүгә зур игътибар бирелә. 2017–2018 нче уку елында 15 татар теле укытучысы методик сертификация буенча яңа проектта катнаша. Алар рус телле балаларны Валерия Мещерякова системасы буенча өйрәтә.

Әйтергә кирәк, яңа системаның үзенчәлеге шунда: башлангыч сыйныфларда рус телле балаларга татар теле өйрәтү ирекле уен формасында алып барыла. «Барлык балалар да татар телендә сөйләшеп китә алмый. Бу укыту методикасы белән бәйле. Дәреслекләр - укытучы

эшенең коралы гына, иң мөһиме – предметны өйрәтү методикасы, ягъни дәрес алымнар, метод һәм технологияләр куллану», – дип белдерә республика Мәгариф һәм фән министрлыгының өстәмә һөнәри белем бирүне үстерү бүлеге башлыгы Роза Шәяхмәтова. 19 нчы мәктәп җирлегендә һәр атна саен Яр Чаллы шәһәре тьюторлары әлеге системага өйрәтү буенча укулар оештыра. 2018 нче елның 23 нче мартында Р.Р. Нигъмәтуллина һәм В.Н. Мещерякова белән берлектә 27 нче мәктәп җирлегендә татар теле һәм әдәбияты укытучыларының республика семинары узды. Семинар эшчәнлегендә балалар бакчаларында татар теленә өйрәтүче тәрбиячеләр, Алабуга, Менделеевск, Яр Чаллы муниципаль районнарының милли мәгариф вәкилләре, тьюторлар катнашты. Әти-әниләрне кызыксындыру максатыннан, В.Н. Мещерякова системасына корылган дәрес фрагментлары күрсәтелде.





Моннан тыш, 4 укытучы “Сәлам” УМК апробациясендә катнаша.

**Татар телен укыту буенча тьюторлар**

| **№ п/п** | **Ф.И.О.** | **Эш урыны** |
|---|---|---|
| **В.Мещерякова системасы буенча укыту** | | |
| 1 | Ирназарова Л.Р. | 5 нче мәктәп |
| 2 | Исмәгыйлева А.А. | 5 нче мәктәп |
| 3 | Никитина А.Е. | 10 нчы мәктәп |
| 4 | Нурмиева Р.Р. | 10 нчы мәктәп |
| 5 | Галиева Р.Р. | 11 нче мәктәп |
| 6 | Бәдретдинова Л.М. | 11 нче мәктәп |
| 7 | Идрисова Г.М. | 19 нчы мәктәп |
| 8 | Фәләхиева Ф.И. | 19 нчы мәктәп |
| 9 | Сибгатуллина Г.Г. | 27 нче мәктәп |
| 10 | Александрова А.И. | 27 нче мәктәп |
| 11 | Шәймөхәмәтова Л.З. | 29 нчы мәктәп |
| 12 | Мөбарәкшина Р.Р. | 32 нче гимназия |
| 13 | Хәбибуллина Г.М. | Кызыл Чишмә мәктәбе |
| 14 | Каюмова Р.Ф. | 33 нче мәктәп |
| 15 | Вәлиева А.Г. | 9 нчы мәктәп |
| **“Сәлам” УМКсын гамәлгә кертү** | | |
| 3 | Гайфуллина И.Р. | 7 нче мәктәп |
| 4 | Галиева Л.Ф. | 7 нче мәктәп |
| 7 | Хәнәфиева Л.Ф. | 29нчы мәктәп |
| 8 | Тимергалиева А.М. | 14нче лицей |

Йомгак ясап шуны әйтәсе килә: Түбән Кама муниципаль районы мәгариф идарәсе милли мәгариф торышын үстерүгә һәм “Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү” программасын тормышка ашыруга зур җаваплык белән карый. Укыту программаларындагы үзгәрешләр һәм татар телен укыту күләме кимүенә карамастан, туган телебезнең торышы, аны саклап калу һәм үстерү, халкыбызның иң күркәм сыйфатларын кулланып, балаларга тәрбия бирүдә тырышлык күрсәтү, башка милләт вәкилләре белән дус һәм тату яшәүне тәэмин итүдә максатчан эш алып барыла.

# В.Н. МЕЩЕРЯКОВА АВТОРЛЫК СИСТЕМАСЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Сибгатуллина Гөлчәчәк Гайнетдин кызы,***
***Александрова Алсу Исмәгыйль кызы,***
*МБББУ "27 нче урта мәктәп" татар теле һәм әдәбияты укытучылары*




Бүгенге көндә татар теле һәм әдәбияты укытучыларын телебезнең язмышы бик борчый. Беркемгә дә сер түгел: бүген телебезнең хәле мактанырлык түгел, татар телен белү дәрәҗәсе түбән булган балалар саны арта. Моңа төп сәбәп – ихтыяҗның кими баруыдыр. Кайбер ата-аналарның, балаларның да телне укытуга карашлары бик уңай түгел. Шулай да бирешергә исәп юк. Телебезне саклап калу, балаларның татар телен өйрәнүгә кызыксынуын үстерү өчен, яңа алымнар эзлибез, яңа педагогик технологияләрне өйрәнеп, укыту-тәрбия эшенә кертергә тырышабыз. Башка милләт балаларында татар телен өйрәнүгә кызыксынуларын арттыру максатыннан, 2016-2017 уку елыннан «Татарстан Республикасы мәктәпләренең рус телле төркемнәрендә эшләүче татар теле укытучыларын методик сертификатлаштыру» проекты гамәлгә ашырыла башлады. Шул уңайдан без ике укытучы быелгы уку елында рус телле беренче сыйныф укучыларын В. Н.Мещерякова авторлык системасы буенча укыта башладык. Нәтиҗәсе куанырлык: балаларда телгә кызыксыну артты, дәресләр кызыграк уза, үзебез дә җанланыбрак эшли башладык.

В.Н. Мещерякова авторлык системасының төп максатларының берсе – мәктәптә татар телен предмет буларак өйрәнүгә карата киеренкелекне киметү, уңай булмаган фикер-мөнәсәбәтләрне юкка чыгару, йомшарту.

Икенче максат – рус телле балаларны татарча сөйләшергә өйрәтү, сөйләмгә чыгару, икенче төрле әйткәндә, коммуникатив компетенцияләрне булдыру. Ул татар телен уку-укытуда хәл ителмәгән үзәк проблемаларның берсе – рус төркемнәрендә татар телен өйрәнүгә каралган сәгатьләр санының гамәли нәтиҗәләр белән туры килмәвенә бәйле.

Әлеге методика авторы баланы башта сөйләмгә, аннан гына тел үзенчәлекләренә өйрәтү кирәк дигән фикерне яклый. Шуңа күрә башлангыч этапта лексиканы өйрәтүгә зур өстенлек бирелә, ә язу юк дәрәҗәсендә.

Методиканың традицион системадан аермалы яклары күп. Дәрес тулысынча уенга корылган. Өстәвенә, алар төрледән-төрле һәм игътибарны, коммуникатив күнекмәләрне үстерүгә юнәлдерелгән.

Система психологик киеренкелек тудырмыйча, димәк, тел барьерын булдырмыйча укыту мөмкинлеге концепциясенә корылган һәм эзлекле рәвештә тыңлап аңлау – сөйләү – уку – язу – тел анализы аша сөйләм күнекмәләрен үстерүне күздә тота. Монда балаларның яшь һәм психофизиологик үзенчәлекләре бик нык исәпкә алынган. Ул да булса:

1) тел өйрәнүдә табигыйлеккә таяну;
2) ишетеп аңлау (аудирование);
3) психологик рәхәтлек;
4) тел мохитенә чумдыру;
5) чит телне өйрәнүне баланың шәхси үсешенә, иҗади сәләтен ачуга юнәлтү.

Нәрсә ул табигыйлеккә таяну? Ул – балаларның 9-10 яшькә кадәр предметларны, төрле образларны инстинктив рәвештә кабул итү, истә калдыру сәләтенә таяну. Бала үз туган телендә кечкенәдән үк ничек сөйләшергә өйрәнсә, шул рәвешле чит телне дә отып ала. Балаларның баш миендә, үзләштерелергә тиешле калыпларны кабат-кабат тыңлау, ягъни аудирование аша, өйрәнелә торган телнең төп структурасы-образы тудырыла. Ни рәвешле? 9 яшькә хәтле сөйләм механизмы сыгылмалы, шуңа күрә табигый, ягъни кат-кат ишетү аша, тел образын тудыру юлын сайларга кирәк. Ятлату, мәҗбүр итү, бер телдән икенче телгә турыдан-туры тәрҗемә итүгә дә юл куелмый. Кечкенә баланы, мәҗбүр итмичә, ничек сөйләмгә чыгарырга? Әлбәттә, уен аша. Чөнки уен – бу яшьтәге баланың төп эшчәнлеге ул.

Дәрестә уңайлы, рәхәт атмосфера тудыру бик мөһим. Дәрескә балалар теләп йөрергә тиеш. Дәрестә киеренкелек булмасын өчен, тоташ төрле-төрле уеннарны алыштырып торабыз, сөйләм тән, кул, йөз хәрәкәтләре белән бергә аралаштырып барыла. Төп дәрес тибы – ул сөйләм телен үстерү дәресе, ә төп дәрес формасы – уен. Ул уку дәресләре һәм кереш дәрес, контроль дәресләр белән аралашып барыла.

Уку дәресләрендә без җырлыйбыз, келәмгә түгәрәкләнеп утырып, лото, домино уйныйбыз; кереш дәрестә аудиодәрес тыңлыйбыз, кайбер уеннарны уйнап карыйбыз; контроль дәрестә укучылар эш дәфтәрендә эшли: рәсем ясыйлар, рәсемнәрне төрле буяуларга буйыйлар, бераз язалар. Эшләрне папкага җыеп, уку елы ахырында әти-әниләре белән бергә балалар китапчыклар тегә.

Укытучының ялгыш җавап биргән укучының хатасына мөнәсәбәт белдерүе дә без гадәтләнгәннән аерылып тора. “Юк, дөрес түгел, утыр,” – дигән сүзләр юк.

Дәрестә берничә кагыйдәнең үтәлүе мәҗбүри. Беренче кагыйдә: татарча гына сөйләшү. 4 нче дәрестән башлап, укучылар өчен “рус теле ябыла”. Баштагы 3-4 атнада укытучы әле рус теленә мөрәҗәгать итә, чөнки яңа уеннарның кагыйдәләрен аңлатырга кирәк була. Рус телен дәрестә куллану акрынлап кими бара һәм 2 нче чиректә без инде тулысынча татар теленә күчәбез.

Тел мохитенә чумдыру ничек башкарыла? Беренчесе – ул татарча гына сөйләшү ихтыяҗын тудыру. Уенда катнашу өчен татарча ниндидер сүз әйтү кирәк. Һәм дәрестә русча сөйләшмәү таләбе дә эшли. Ә ничек сүз мәгънәсен җиткерергә соң? Моның өчен без күрсәтмәлелеккә басым ясыйбыз. Ул - рәсемнәр, уенчыклар да, тән, кул, йөз хәрәкәтләре дә. Аңлашу өчен, тел образын тудыру өчен бик кирәкле аралашу элементлары. Шуңа күрә ниндидер сүзне яки структураны хәрәкәт белән күрсәтәбез. Сүз, предмет, төшенчәләрне күрсәтү уңайсыз булган очракта,рәсем яки уенчык кулланабыз.

Сөйләм телен үстерү курсында укучыларның шәхси үсеше өчен шартлар тудыруга да әһәмият бирелә. Балаларда уеннан укуга күчү активлыгы формалаштырыла. Алар курыкмыйча такта янына чыгарга, төркем белән идарә итәргә өйрәнәләр. Даими рәвештә төрле рольләргә кереп уйнау (мәсәлән, сатучы, кибетче, укытучы һ.б.) социальләшүгә, ягъни төрле җәмгыяви структураларга кереп, шәхеснең продуктив үсешенә йогынты ясый.

Дәвамчанык һәм материалның гел кабатланып торуы материалның горизонталь тематик планлаштыруында чагылыш таба. Телнең теләсә кайсы берәмлеге, сөйләм структурасы өч этаптан тора: ишетү, камилләштерү, ныгыту. Шул рәвешле, өйрәнгән материал кыска хәтердән озын хәтергә күчә, онытылып калмый.

Дәрес структурасы укучыларның эчке һәм тышкы активлыкларын саклануны куздә тотарга, ягъни һәр ике категория дә дәрестә үзләрен җайлы итеп хис итәргә тиеш булалар.

В.Н. Мещерякова системасындагы лексик берәмлекләр, сөйләм структуралары шулай итеп сайланган ки, алар көндәлек тормышта да һәм сөйләмдә дә иркен кулланырлык.

# МИНЕМ, СИНЕҢ, АНЫҢ АЛМАШЛЫКЛАРЫН КУЛЛАНУНЫ СӨЙЛӘМДӘ НЫГЫТУ

***Сибгатуллина Гөлчәчәк Гайнетдин кызы,***
***Александрова Алсу Исмәгыйль кызы,***
*МБББУ “27 нче урта мәктәп” татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

 

**1 нче сыйныф, рус төркеме**

*Максатлар:*

1. Минем, синең, аның алмашлыкларын куллануны сөйләмдә ныгыту.
2. Сорау кую ысулларын һәм дөрес җавап бирә белү күнекмәләрен камилләштерү, тартым кушымчалары турында белгәннәрне ныгыту.
3. Әти-әнигә, гаилә әгъзаларына ихтирам тәрбияләү.

*Эш формалары*: индивидуаль, парларда, төркемләп, фронталь.

*Дәреснең тибы*: катнаш.

*Җиһазлау*: рәсемнәр, пиктограммалар, уенчыклар.

**Дәрес барышы:**

*I. Психологик уңай халәт булдыру.*

– Исәнмесез, балалар!

– Исәнмесез!

– Безнең бүлмәбез чистамы?

– Әйе, чиста.

– Минем урындыгым чиста, яхшы, яңа. Ә синең урындыгың чистамы?

– Әйе, чиста.

– Минем урындыгым чиста, ә синең урындыгың чиста түгел. Гафу ит!

Менә чиста урындык. Ал.

– Хәлләрегез ничек?

– Яхшы. Ә сезнең хәлләрегез ничек?

– Минем дә хәлләрем яхшы. Укучылар, дәресне башлыйбыз.

*II. Белемнәрне актуальләштерү.*

– Әйдәгез, “телефон–телефон” уйныйбыз! Бу нинди номер?

– 14, 17, 19.

– Номерны сорагыз!

– Миңа 15–16–17 номерын бирегез, зинһар. (Укытучы укучыларга номерлар тарата)

– Арина, хәзер син авыру бала. Бу синең гаиләң. Синең гаиләң дусмы?

– Әйе!

– Монда ят. Йокла! Син авырыйсың. Ә мин сиңа сәлам әйтәм. Менә, телефон номерлары. (Укытучы телефон номерларын ала һәм теләсә кайсы бер номерны укый. Әгәр “абонент” җавап бирмәсә, укытучы: “Элемтә начар, телефон җавап бирми. Әйдәгез, тагын шалтыратабыз”,– ди һәм шул ук номерны ачыграк һәм әкренрәк әйтә.)

– Алло!
– Алло! Исәнмесез!
– Исәнмесез!
– Мин Лилия апа, Аринаның укытучысы. Ә сез кем?
– Ә мин Аринаның әнисе.
– Арина өйдәме?
– Өйдә.
– Трубканы Аринага бирегез әле, зинһар (Әни–бала трубканы “авыру” балага бирә). Исәнме, Арина! Синең хәлләрең ничек? Яхшымы?
– Яхшы түгел.
– Мәктәпкә киләсеңме?
– Юк!
– Сиңа балалар сәлам әйтәләр.
– Рәхмәт.
– Ә син балаларга сәлам әйтәсеңме?
– Мин дә сәлам әйтәм.
– Рәхмәт! Әниеңә дә, әтиеңә дә сәлам әйт. Сау бул, Арина!
– Сау булыгыз!

Тактада ө,е хәрефләре төшереп калдырылган сүзләр: өч, төлке, муен, өй, өстәл, итек. Укучыларның кулында әлеге хәрефләр язылган карталар. Балалар дөрес хәрефне күтәрәләр һәм бергә укыйлар, хәрәкәтләр ярдәмендә әлеге сүзләрне күрсәтәләр.

Укучылар, әйдәгез, уен уйныйбыз! Безнең кабинетыбыз җылымы, салкынмы? (зур–кечкенә, чиста–пычрак, начар–яхшы, матур–ямьсез) Шкаф (тәрәзә, парта, ишек, өстәл, урындык, такта, сәгать) кайда?

– Менә, шкаф.
– Пыяла кайда бар?
– Шкафта (лампада, күзлектә, рәсемдә, сәгатьтә) дә бар.
– Синең өйдә ничә бүлмә бар? Алар нинди? Аерма бармы? Ә зур бүлмәдә нәрсә бар? Тегендә нәрсә бар?
– Тегендә шкаф бар.
– Бүлмәдә шкаф бар. Тегендә тагын нәрсә бар?

*III. Әңгәмә. Уку мәсьәләсен кую.*

1. Пиктограммалар салынган сумка; пиктограммалар, укучылар укый алсыннар өчен, язулы якларын өскә каратып куелган. Кием, җиһаз, хайваннар, кошлар һәм башка кирәкле рәсемнәр.

– Монда ничә рәсем бар?
– Күп!
– Бу сумкага нәрсәләрне салабыз?
– Бу сумкага киемнәрне, кошларны, хайваннарны салабыз. Бу – шкаф. Ул – җиһаз.

(Укытучы рәсемнәрне тиешле сумкага салып бара).

– Кирилл, хәзер син сал.
– Бу – куян. Ул – хайван. (Балалар бөтен рәсемнәрне дә тиешле сумкаларга бүлеп урнаштыралар).

2. “Куян–бүре” уены.

3. “Генерал” уены. Вика, монда кил! Вика, хәзер син солдат, ә мин генерал. Мин сиңа команда бирәм, ә син “Тыңлыйм, иптәш генерал!”– дип әйт.

Мин сиңа “Шулай ит,” – дип әйтәм, ә син команданы үтә.

– Йокла! Шулай ит! Бар! Йөгер! Сикер! Тор! Юын! Киен! Яз! Укы! Аша! Эч! Алай итмә! Ела!

4. (Бичура, кулына сумка тоткан. Сумкада гаилә темасына рәсемнәр). Балалар, тыңлагыз! Ишетәсезме? Кемдер тегендә кыштыр-кыштыр килә. Карагыз! Күрәсезме? Бу кем? Син кем?

– Әйтмим, бел!

– Син куянмы?
– Юк, мин куян түгел.
– Син Шүрәлеме?
– Юк, мин Шүрәле түгел.
– Белмим, әйт!
– Әйтмим!
– Әйт, әле зинһар! (Сорауны дөрес итеп биргән укучының колагына – Мин Бичура! – дип әйтә). Ә сезнең исемегез ничек?
(Укучылар хор белән һәркайсы үзенең исемен әйтә).
– Әйдәгез, дус булабыз! (Бер–берсенең кулларын кысышалар.) Әйдә, дус булабыз!
– Әйдә!
– Хәзер без дуслар!
– Ә хәзер, әйдәгез уйныйбыз!
5. Бичура:
– Синең бу чалбарың шундый матур, ә синең тагын бер чалбарың бармы? Ул өйдәме? Ул нинди? Синең ничә чалбарың бар? Аның өч чалбары бар! (Берничә бала белән киемнәр турында сөйләшәбез).
6. (Бичура өчен яңа пәлтә шкафта яшерелгән. Бичура елый)
– Нәрсә булды? Нигә елыйсың?
– Минем кием пычрак, ямьсез. Миңа чиста кием кирәк.
– Бездә пәлтә бар. Ул кайда? Мин әйтмим. Бел! Балалар, ә сез аңа булышыгыз!
– Өстәл!
– Ул өстәлдәме?
– Юк! Ул өстәлдә түгел.
– Шкаф!
– Ул шкафтамы?
– Әйе, ул шкафта. Менә, пәлтә, ул сиңа бүләк.
– Рәхмәт. Миңа бу пәлтә бик ошый!
7. (Бер яклы баскыч+секундларны күрсәтә торган сәгать яки секундомер+пиктограммалар: чиста, яңа, матур). Минем–синең киемең. (Баскычтан югарыга күтәрелеп, “5”ле билгесе алу өчен,үзенең һәм Бичураның киемен чагыштырып, укучы бер минут эчендә 5 җөмлә әйтергә тиеш. “4” билгесе алу өчен – дүрт җөмлә. Һәр бала да бу тема буенча билге алырга тиеш).
*IV. Ныгыту.*
1. (Сумка. Анда Бичураның гаиләсе рәсеме) Сумкада нәрсә бар?
– Бу минем гаиләм.
– Ә синең гаиләңдә кем бар?
– Әйтмим, бел!
– Синең әниең (әтиең, дәү әтиең, дәү әниең) бармы?
– Әйе! Минем әнием бар.
– Синең гаиләң дусмы?
– Әйе. Минем гаиләм дус. Ә сез дуслармы?
– Әйе! Без дуслар!
*V. Рефлексия.*
1. Кемнең борыны зур (кечкенә?)
– Минем!
– Кемнең чәче кыска?
– Минем чәчем кыска!
2. Әйдәгез, бармакларны саныйбыз! Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, унбер, унике, унөч, ундүрт, унбиш, уналты, унҗиде, унсигез, унтугыз, егерме.
*VI.Йомгаклау.*
Гафу итегез, балалар! Вакыт үтте. Дәрес бетте. Сау булыгыз!

## РУС ТЕЛЛЕ УКУЧЫЛАРНЫ “СӘЛАМ!” УМКсы НИГЕЗЕНДӘ УКЫТУ




***Хәнәфиева Ләйсән Файзехан кызы,***
*МБББУ “29 нчы урта мәктәп”*
*татар теле  һәм әдәбияты укытучысы*

Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы житәкчелегендә “Сәлам!” укыту-методик комплексы буенча апробация эше республика мәктәпләрендә киң колач җәйде. 2017-2018 нче уку елында Түбән Кама шәһәренең 29 нчы мәктәбе дә шушы апробация эшендә бик актив катнаша.

**Рус телле укучыларны татарча иркен аралашырга өйрәтү максатыннан, мин шушы эшемне 1 нче г сыйныф укучылары белән башлап җибәрдем.**




“Сәлам!” укыту-методик комплекты дәреслек, иҗади мөмкинлекләр биргән эш дәфтәре һәм укытучы китабыннан тора. Укытучыга дигән методик китапта дәрескә тәкъдимнәр, яшь үзенчәлекләренә туры килгән уеннар, кызыклы һәм мавыктыргыч күнегүләр тупланган. Әлбәттә, бу методик әсбап минем дәрескә әзерләнүемне бик күпкә җиңеләйтте. Моннан тыш, дәреслектә рәсемле сүз өйрәтү карточкалары, эш дәфтәре өчен стикерлар да бар. «Сәлам!» китабы иллюстрация ягыннан бик отышлы, рәсемнәре күп, балаларга бу бик кызыклы. Яңа дәреслектә тел үзләштерү материалы бик җиңел итеп тәкъдим ителгән. Беренче сыйныфта урыс телле балалар 160 сүзне һәм 30 сөйләм калыбын үзләштерергә тиеш. Дәрес уен аша бара. Яңа гына мәктәп бусагасын атлап узган бала күбрәк уйнарга тели. 15 темалы дәреслекнең һәр модулендә яңа өйрәнгән сүзләр белән кызыклы җырлар, мавыктыргыч уеннар, тормышчан диалоглар кергән аудиоматериаллар да бар. Дәреслекнең аерым сайты да бар **http://selam.tatar/**. Укучылар һәм укытучылар логин-сер сүзләре белән кереп, булган материалны кабатларга мөмкинлек тудырылган аудиоларны тыңлый алалар, интерактив уеннарны да куллану мөмкинлеге бар.



Минем укучыларым татар теле дәресләрен көтеп алалар, татарча сөйләм хәтерләренә тизрәк сеңә, уеннар ярдәмендә алган белемнәрен өйдә әти-әниләре белән дәвам итәләр. Боларның күпчелеге – татар теле өчен яңалык, моңа кадәр мондый дәреслекләрнең булганы юк. Бу эшне яңа уку елында уңышлы дәвам итәрбез дип ышанып калабыз.

## БЕЗНЕҢ УҢЫШЛАРЫБЫЗ
## ТАТАР ТЕЛЕННӘН VI ХАЛЫКАРА ОЛИМПИАДА

### БӨТЕН ТАТАР БЕР КАЗАНДА ҖЫЕЛДЫ



***Сөнгатуллина Ләйлә Мөхәммәт кызы,***
*Түбән Кама муниципаль районы*
*Муса Җәлил исемендәге 1 нче гимназиянең*
*туган тел һәм әдәбият укытучысы*

Телебезнең киләчәге “шик астына” куелган заманда милләтебезнең беркайчан да бетмәсен дәлилләүче чарада катнашырга туры килде миңа. 22-25 нче апрельдә мәркәзебез Казанда татар теле һәм әдәбияты буенча VI Халыкара олимпиада узды. Дөньяның кайсы җиреннән генә җыелмаган иде монда татарлар! Кытай, Финляндия, Төркия, Казахстан, Япония, Франция, Эстония, Индонезия... Гаҗәп бит!

Әлеге олимпиадада һәр ел саен безнең муниципаль районыбыздан да укучы балаларыбыз катнашып, урыннар яулап, лауреат дәрәҗәсенә җитеп, безне куандырып торалар. Бакый Урманче исемендәге 2 нче гимназия укучылары Хасаншина Ләйлә (9 А сыйныфы), Сабирова Ләйсән (8 сыйныф) 2016 елда призер булып кайттылар. 2017 нче елда исә 35 нче лицейның 10 нчы сыйныф укучысы Андрющенко Елена лауреат исемен яулап кайтты. Муса Җәлил исемендәге 1 нче гимназиянең 10 нчы сыйныф укучысы Сөнгатуллина Фәридә, бик уңышлы чыгыш ясап, 2018 нче елда олимпиаданың лауреаты булды. Фәридә бу җиңүен иң зур бүләге дип саный.

Әлеге олимпиаданың татарларны бергә туплау өчен бик зур, кирәкле чара булуына ышанып кайтты ул аннан. Яшьтәшләре булган чит илдән килгән милләттәшләребез белән дуслашып та, туганлашып та өлгерделәр. Һәр сүзнең тәмен белеп, ашыкмыйча, бер генә чит тел сүзен катыштырмыйча, хөрмәт белән сөйләшә белүләре һәркемне сокландырды. Чын япон егете Чихиро Тагучи безнең газиз телебезне бик яратып өйрәнә икән. “Татар теленең яңгырашы матур!”- дип сөйләгәнен ишеткәч, аның алдында оят та булып китте, чөнки телебезне белмәгән милләттәшләребез дә бар бит. Финляндиядән килгән Ильяс һәм Касыйм Каадер кебекләрне үрнәк итеп күрсәтергә, алар турында күбрәк сөйләргә кирәк. Гранприны яулаган Ильяс Каадер сөйләме белән дә, белеме белән дә дәрәҗәсен аклады. Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры сәхнәсенә чыгып милләтебезнең киләчәге турында уйлануларын җиткергәндә, залда утыручы һәркемнең күзе яшьле иде.

## БӨТЕНРОССИЯ “ИЛҺАМ” ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР БӘЙГЕСЕ ЛАУРЕАТЫ



***Шәймәрдәнова Мөслимә Габделхәй кызы,***
*Югары Чаллы урта гомуми белем бирү мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Нәфыйкова Рания үзен башлангыч сыйныфлардан ук бик тырыш, үҗәт һәм укуга сәләтле итеп танытып өлгергән иде. Ә бишенче сыйныфта ул укыган сыйныфта дәресләр алып бара башлагач исә, мин аның башка балалардан бик актив булуы, уку материалын бик җиңел

үзләштереп баруы, өйгә бирелгән иҗади эшләрне бик теләп һәм бик яхшы башкаруы белән дә аерылып торуын күрдем. Ранияне 5нче сыйныфтан ук татар теле һәм әдәбияты фәннәреннән олимпадага әзерләдем һәм ул, ике фәннән дә, дөресрәге дүрт фәннән (рус теле укытучысы аны шулай ук рус теле белән рус әдәбиятыннан алып барган иде) призлы урыннар яулап, безне сокландырды. Ә 6нчы сыйныфта исә ул инде өч фәннән дә муниципаль турда җиңүче булды. Бу уку елында исә Рания муниципаль турда татар теле һәм әдәбияттан призлы урыннар алса, рус әдәбияты буенча фән олимпиадаларының республика турында да призлы урын яулады.

2016 нчы елда без Рания белән Туфан Миңнуллин исемендәге укытучыларның һәм укучыларның III республика конференциясендә “Әдәпкә күнсәң – адәм булырсың, яманга күнсәң – әрәм булырсың” мәкаләсе белән катнаштык. Әлеге мәкаләсендә Нәфыйкова Рания тормышыбызда шактый тамыр җәеп өлгергән проблема – үзебез яшәгән тирәлегебезгә карата битарафлыгыбыз, табигатькә саксыз карашыбыз нәтиҗәсендә туган экологик мәсьәләне күтәреп чыгып, бәйгедә лауреат исеменә лаек булган иде. 6нчы сыйныфта Рания, рус телендә хикәя язып, региональ иҗади бәйгедә һәм “Икенче Рәсәйкүләм Пушкин укулары” бәйгесендә катнашты һәм икесендә дә призлы урыннарга лаек булды. Шул җиңүләр тәэсирендә илһамланган Рания: “Апа, тикшереп чыга алмассызмы?” – дип, миңа татарча үзе язган хикәясен алып килде. “Булмас димә, дөнья бу!” дип аталган әлеге хикәягә бик аз гына төзәтмәләр кирәк иде. Минем киңәшләрне истә тотып төзәткәннән соң, Рания аны миңа алып килде, берәр бәйгедә катнашырга теләген белдерде. Ул вакытта уку елы дәвамында була торган җитди бәйгеләр калмаган иде инде. Әлеге хикәяне без бу уку елында яшь иҗатчылар арасындагы иң дәрәҗәле һәм бәяле исәпләнгән “Илһам” бәйгесенә җибәрергә булдык һәм ялгышмадык. Әлеге бәйгедә “Лауреат” исеменә лаек булу Ранияне тагын да канатландырыр һәм тагын да дәртләнеп иҗат итәргә этәрер дип уйлыйм.

Төрле иҗат бәйгеләрендә, тел фәннәре олимпиадаларында актив катнашып, бик еш җиңүләргә ирешүе өстенә, сыйныф һәм мәктәп эшендә кайнарга, бию, спорт түгәрәгенә йөрергә дә вакыт таба ул безнең йолдызыбыз Нәфыйкова Рания Илфат кызы.

## “ИЛҺАМ” КОНКУРСЫННАН ҖИҢҮ БЕЛӘН!

***Гыйманова Илсөяр Гарәфетдин кызы,***
*МБББУ “27 нче урта мәктәп”*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*



Быел алтынчы тапкыр Россия күләмендә мәктәп укучылары арасында “Илһам” әдәби иҗат конкурсы уздырылды. Әлеге конкурсны Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы республиканың Язучылар берлеге белән бергә оештырды. Татар телендә әдәби иҗат белән шөгыльләнүчеләргә дәрт өстәп, талантлы балаларга канат куеп, яңа биеклекләргә, бөеклекләргә юл ачучы гаҗәеп файдалы бер күркәм чара булды ул. Анда барлыгы 1600 бала катнашты, шуларның 35е призлы урын яулады.

Шушы мәртәбәле ярышта безнең кызларның призлы урыннар яулавы белән чын күңелдән горурланабыз. Шәһәребезнең 27 нче урта мәктәбе 10Б сыйныфы укучысы Гыйманова Диләрә икенче дәрәҗәле диплом һәм сертификат белән бүләкләнде. Урта Чаллы мәктәбенең 7нче сыйныф укучысы Нәфыйкова Рания лауреат исеменә лаек булды. Мондый зур, абруйлы конкурсларда беренче чирканчык алган бу балаларга алдагы тормышларында да зур уңышлар телибез. Киләчәктә дә алар сынатмаслар дигән өметтә калабыз. “Илһам” конкурсында канат ярган бу укучыларны яңа офыклар һәм дәрәҗәләр куандырсын!

# АНА ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫЛАРЫНЫҢ БӨТЕНРОССИЯ “ТУГАН ТЕЛ” МАСТЕР-КЛАСС БӘЙГЕСЕ НӘТИҖӘЛӘРЕ



***Клипова Наталья Александровна,***
*учитель русского языка и литературы*
*МБОУ «Гимназия №32» НМР РТ,*
*победитель Всероссийского конкурса*
*мастер-классов учителей родного языка «Туган тел»*

Разгорячённые лица. Сияющие, пытливые глаза. Они спорят и учатся доказывать свою точку зрения. Они пытаются найти истину. В прошлом и настоящем нашей Родины, в литературе, в себе. Они – это мои неугомонные ученики. Идут последние минуты урока-диспута. Звонок…Опять звонок… Ребята не пришли к единому мнению. Но это и не главное. Главное – каждый ученик на уроке рассуждал и отстаивал свое мнение. Но почему так настойчиво звенит звонок? Ах, это уже не школьный. Это телефон.

- Да! Конкурс?... Профессиональный? Конечно, интересно!

*КоооНкурс*. Какое завораживающее слово. Как будто взбираешься на гору. Вот ты на самой вершине. И… Ух! радостно и быстро едешь вниз. Люблю это ощущение стремительности, некой опасности и… полета. Да и какой русский не любит быстрой езды? Прав был Николай Васильевич. Ох, как прав! Как будто всё поставлено на кон и нужно только выбрать правильный курс. Может не случайно *кон-курс*?

Итак, конкурс. Всероссийский конкурс мастер-классов учителей родного языка и литературы «Туган тел». Так…Почитаем положение, что нужно сделать? В первом этапе показать мастер-класс по предмету. Хм… О чем бы рассказать коллегам? Чтобы весело и интересно? Может быть об этимологии? Или о работе с Национальным корпусом русского языка? Решено. Будем совмещать. Голова полна идей, мысли теснят друг друга. Хочется рассказать и о том, и об этом. Стоп. Временные рамки ограничены. Берём только самое-самое. И вот уже учителя играют в слова, знакомятся с НКРЯ, придумывают оригинальные толкования слов. Вот «закладка». Как думаете, что это? В народной этимологии моих коллег это «стукач» или «пьяница».

Кажется, получилось. Играя, открыли новое. Что дальше? Звонок… Снова звонок.

- Готовы представлять город на конкурсе?

Нет, не готова. Но постараюсь. Создать видеоролик «Мой край, моя школа, моя профессиональная деятельность»? За два дня?! Ээх, прокачусь! Теперь уже я звоню. Нужны фото. Спасибо, коллеги, родители, милые мои детки! Есть ролик!! Можно остановиться и подумать. Подумать о себе как учителе. Ведь тема обязательного эссе ««Моё педагогическое мастерство». Как это важно! Остановиться и подумать: «А на своем ли я месте?»

